Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советының сиксән сигезенче утырышы

# КАРАР

28 октябрь, 2019 ел № 161

**«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 октябрендә кабул ителгән 87 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законнары, һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 статьясына, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы федераль законы нигезендә, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 87 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 пунктчасын «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган) » дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.2. 2 пунктның 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата салым базасының **0,15 % ы**;»;

1.3. 2 пунктның 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата салым базасының **0,3% ы**

- шәхси торак төзелеше объектларын урнаштыру өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен;»;

1.4. 5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Салым түләүнең киләсе тәртибен билгеләргә:

- салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче кварталдан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1.1, 1.2, 1.3 пунктлары 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1.4 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

4. Әлеге Карарны «Вперёд» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге

СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1633000835

Ф.Д. Фәезов